КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 230

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2022 ел, 4 июль, 620 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2022 ел, 4 июль, 620 нче карарына

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 ноябрь, 1253 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елда Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалауны белән тәэмин итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм мәдәният, яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне (алга таба - хезмәткәрләр) шифаханә-курорт дәвалауны белән тәэмин итү буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен (алга таба - Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе) расларга.»;

$2^1$ пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «2022 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2023 елның 31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «, Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт оешмалары, Татарстан Республикасында муниципаль социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү оешмалары, Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт оешмалары, Татарстан Республикасында муниципаль социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт оешмалары, Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалауны тәэмин итү өлешендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «һәм муниципаль хезмәткәрләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслауны «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты

турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырырга.»;

5 пунктта:

икенче абзацта «2022 ел» сүзләрен «2023 ел» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрнең шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе;»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе (алга таба - Тәртип) 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык), Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм мәдәният, яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне (алга таба - хезмәткәрләр) Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе курорт фонды Дәүләт реестрына кертелгән һәм Министрлык белән Сертификатлар нигезендә шифаханә-курорт дәвалануы хезмәткәрләренә хезмәт күрсәтү турында килешү төзегән шифаханә-курорт дәвалануы бирүне гамәлгә ашыручы шифаханә-курорт оешмасына шифаханә-курорт дәвалануына юллама (алга таба - тиешенчә Сертификат, юллама) түләүгә (өлешчә түләүгә) сертификат бирү юлы белән шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү шартларын һәм тәртибен билгели (алга таба - тиешенчә шифаханә-курорт оешмасы, Килешү).»;

1.4 пунктта «2022 елның 1 декабренә кадәр, 1 декабрьне кертеп» сүзләрен «2023 елның 1 декабренә кадәр, 1 декабрьне кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «2022 елда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«КЗ - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, Татарстан Республикасында муниципаль сәламәтлек саклау оешмалары хезмәткәрләре;

КОиН - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, Татарстан Республикасында муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре;

КК - Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, Татарстан Республикасында муниципаль мәдәният оешмалары хезмәткәрләре;

МС - Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр.»;

2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык карамагындагы, йә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, йә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, йә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, йә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, йә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, йә муниципаль социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, йә муниципаль физик культура һәм спорт оешмасы, йә муниципаль сәламәтлек саклау оешмасы, йә муниципаль мәгариф оешмасы, йә муниципаль мәдәният оешмасы белән, йә яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләре булу турындагы йә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт узу турында белешмәләр;»;

2.3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык карамагындагы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, муниципаль социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, муниципаль физик культура һәм спорт оешмасы, муниципаль сәламәтлек саклау оешмасы, муниципаль мәгариф оешмасы, муниципаль мәдәният оешмасы белән, яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылу (булмау) турындагы, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт туктатылу (булмау) турында белешмәләр;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәткәрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булуы;»;

җиденче абзацта «2022 ел» сүзләрен «2023 ел» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта «2022 елның 1 августына кадәр» сүзләрен «2023 елның 1 апреленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «2022 елга» сүзләрен «2023 елга» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның дүртенче абзацында «2022 елның 1 декабренә кадәр» сүзләрен «2023 елның 1 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктта «2022 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «2023 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктта «2022 елда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.
әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;
әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә 7 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 март, 230 нчы карары редакциясендә);

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;
әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 март, 230 нчы карары редакциясендә);

әлеге Тәртипкә 6 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;
әлеге Тәртипкә 7 нче кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә 7 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 11 март, 230 нчы
карары редакциясендә);

әлеге Тәртипкә 8 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин